**Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Бирючевка авылы № 1 «22»гыйнвар 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 август 97 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (12.11.2015 №14, 13.12.2016 №46, 23.04.2019 №129, 03.02.2020 №160, 24.02.2021 №2, 23.09.2021 №15, 18.04.2023 №15, 20.10.2023 №31 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 август 97 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (12.11.2015 №14, 13.12.2016 №46, 23.04.2019 №129, 03.02.2020 №160, 24.02.2021 №2, 23.09.2021 №15, 18.04.2023 №15, 20.10.2023 №31 номерлы карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең 9.2 бүлеген 1.1 пункты белән тулыландырып, түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешне кертергә:

«1.1. Муниципаль хезмәткәр «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтларын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында әлеге Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән очракта, җаваплылыктан азат ителә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Г.Солтанова